ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

21 август 2025 ел

№ 6138

Башкарма комитетның «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2024 елның 13 июнендәге 3756 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 5324 номерлы, 2025 елның 14 мартындагы 1979 номерлы Карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 9 552,2 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2024 ел – 2 340,3 мең сум, 2025 ел – 6 055,3 мең сум, 2026 ел – 578,3 мең сум, 2027 ел – 578,3 мең сум.»;

2) «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәмчыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганагы | 2024 (мең сум) | 2025 (мең сум) | 2026 (мең сум) | 2027 (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль бюджет | 2 340,3 | 6 055,3 | 578,3 | 578,3 | 9 552,2 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 2 340,3 | 6 055,3 | 578,3 | 578,3 | 9 552,2»; |

- 4 бүлектә:

- 4 бурычның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | «Автокаланың яшь эшмәкәре» конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2024-2027 еллар | Конкурста җиңүчеләр саны, кеше | 5 | 6 | 6 | 6 | 6 | 112,8 | 3612,8 | 112,8 | 112,8 | Уңышлы яшь эшмәкәрләрне ачыклау, яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясен формалаштыру |

- 5 бурычның 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «16. | Шәһәр Советының йомгаклау утырышы кысаларында күргәзмә үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Күргәзмәдә катнашучылар саны, берәмлек | 40 | 45 | 45 | 45 | 45 | 1762,0 | 2277,0 | 300,0 | 300,0 | Яңа кооперация элемтәләрен үстерү өчен предприятиенең элемтәләрен киңәйтү»; |

- «Программа буенча барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Программа буенча барлыгы: | 2 340,3 | 6 055,3 | 578,3 | 578,3»; | |

- 6 бүлектә таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Чыганаклар һәм чыгымнарның юнәлешләре | Финанслау күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | шул исәптән еллар буенча | | | |
| | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 9 552,2 | 2 340,3 | 6 055,3 | 578,3 | 578,3». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов